
**Сәйфетдинов Әмир Галиулла улы.**

*Мин, Сәйфетдинов Әмир Галиулла улы, 1941нче елның 30 нчы июлендә туганмын. Битаман мәктәбендә 7 класс белем алдым. Усадта 1962 нче елны трактористлыкка укыдым.*

*Әти сугышка киткәндә 1 айлык бала булып калдым. 1941 нче елда әти сугышка китте һәм шунда үлеп калды. Шуннан ачлык башланды. Бабайны карадык. Ашарыбызга кузгалак, кычыткан, күкәрин бәрәңгесе иде. Урманнан утын ташыдык. Шуннан соң тракторда эшләдем. Күңелле вакыйгалар кызлар артыннан йөрү булгандыр инде. Әйе, мин укыдым, ул вакытларда уку булмады инде, “2”легә, “3”легә укыдым. Сугыш барган урыннардан безнең якка яшәргә кайткан кеше булмады, безнең күрше малае гына кайтты. Минем әти аның белән дус булган. Сугышчыларга әни оекбашлар, бияләйләр бәйләп жибәрә иде.*

*Сугыштан соңгы елларда әйбәт яшәдек. Сугыш вакытындагы кебек тугел инде. Яшь буынга теләгем: хәзерге вакытта бар әйберегез дә бар, эстегезгә кияргә киемегез бар, ашарга ризыгыгыз бар, шуның кадерен белеп яшәгез. Яхшы билгеләргә укыгыз. Хәзерге вакытта сугышлар булмасын инде.*